**Китапханә хәбәрләре**

**Китапханә** – беренчедән, матур әдәбият дөньясы булса, икенчедән, тылсымлы вакыйгалар иле дип әйтергә мөмкин. Анда рухи байлык алудан тыш, язучылар белән очрашасың, яңалыкларны белергә омтыласың... Китапханәнең төп байлыгы китаплар булса, иң кадерлесе – андагы китапларны укырга яратучыларның күп булуы. Шуңа да китапханә киштә-киштә китаплары белән генә түгел, ә үзенең укучылары белән яши. Гомуми итеп әйткәндә, алар берсен-берсе тулыландырып, үткәнне онытмаска, бүгенгенең кадерен белергә, киләчәкне күзалларга да өйрәтәләр. Шул максаттан чыгып, китапханәдә төрле әдәби чаралар үтә.

Чаралар, күргәзмәләр, дәресләр үткәрү матур традициягә әйләнде. Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы уңаеннан оештырылган күргәзмә китапханәгә кергән һәркемгә бай, тулы мәгълүмат бирә.






РУС ӘДЕБИЕТЫ